КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 18 апрель г.Казань № 362

2022 елда халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен җайга салына торган тарифлар буенча шәһәр пассажир ташуларын гамәлгә ашыручы автотранспорт предприятиеләренең алынмаган керемнәрен каплау өлешендә финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1.카раргa теркәлгән 2022 елда халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен җайга салына торган тарифлар буенча шәһәр пассажир ташуларын гамәлгә ашыручы автотранспорт предприятиеләренең алынмаган керемнәрен каплау өлешендә финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 18 апрель, 362 нче
карары белән расланды

2022 елда халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен җайга салына торган тарифлар буенча шәһәр пассажир ташуларын гамәлгә ашыручы автотранспорт предприятиеләренең алынмаган керемнәрен каплау өлешендә финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2022 елда халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен җайга салына торган тарифлар буенча шәһәр пассажир ташуларын гамәлгә ашыручы автотранспорт предприятиеләренең алынмаган керемнәрен каплау өлешендә финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы (алга таба - Әлмәт муниципаль районы) бюджетына башка бюджетара трансфертлар (алга таба - башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар 2022 елда бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен акча белән баш эш итүче буларак Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

Әлмәт муниципаль районы бюджетында (җирле бюджетның җыелма бюджет исемлегендә) Әлмәт муниципаль районының финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен аларны үтәүгә кирәкле күләмдә (Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелүгә планлаштырыла торган башка бюджетара трансферт күләмен кертеп) бюджет ассигнованиеләре булу;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар йөкләмәләрен үтәү буенча Әлмәт муниципаль районы йөкләмәсен күздә тоткан башка бюджетара трансфертлар бирү турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк форма буенча килешү (алга таба – килешү) төзү һәм килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

4. Башка бюджетара трансфертларны файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткече булып (алга таба - нәтиҗәлелек күрсәткече), 2022 елда шәһәр пассажир ташуларын башкарганда транспорт хезмәте күрсәтүнең ышанычлылыгы тора, ул "даими шәһәр пассажир ташуларының маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты" күрсәткече ярдәмендә бәяләнә, аның әһәмияте $\geq 0{,}7$ булырга тиеш.

2022 елда даими шәһәр пассажир йөртү маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты ($К_{расп}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_{расп} = \frac{\sum Q_{iрейсрасп}}{\sum Q_{фактрейс}} \geq 0{,}7,$$

монда:

$Q_{iрейсрасп}$ – 2022 елда шәһәр пассажир йөртүләрен i- транспорт төре белән гамәлгә ашырганда расписание белән билгеләнгән рейслар саны;

$Q_{фактрейс}$ – 2022 елга шәһәр пассажир йөртүләрен i- транспорт төре белән гамәлгә ашырганда эшләнгән фактик рейслар саны.

Нәтиҗәлелек күрсәткеченең мәгънәсенә ирешүне бәяләү Министрлык тарафыннан Әлмәт муниципаль районының вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан тапшырылган әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән хисаплар нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен Әлмәт муниципаль районының вәкаләтле җирле үзидарә органы Министрлыкка түбәндәгеләрне кертә:

башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗны финанс-икътисадый нигезләү теркәлгән, ирекле формада язылган башка бюджетара трансферт бирү турында заявка (алга таба – заявка);

вәкаләтле зат тарафыннан расланган һәм Әлмәт муниципаль район бюджетында бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларны үз эченә алган чаралар исемлеген тормышка ашыру буенча Әлмәт муниципаль районның чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган агымдагы финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты (җыелма бюджет исемлеге) турындагы Әлмәт муниципаль районның вәкаләтле органы карарыннан өземтә;

6. Министрлык:

заявканы кергән көнендә теркәүгә ала;

теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә бу Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны карап тикшерә һәм башка бюджетара трансфертлар бирү турында яки башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

7. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән документларны Әлмәт муниципаль районының вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органы тарафыннан тапшырылган документларның, аларда булган белешмәләрнең әлеге Тәртиптә каралган таләпләргә һәм шартларга туры килмәве;

Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.

Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарткан очракта Министрлык карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә бу хакта Әлмәт муниципаль районының вәкаләтле җирле үзидарә органына хәбәр итә.

8. Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә вәкаләтле органы, әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, заявканы кире кагу турында хәбәр

алынган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

9. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык һәм Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы арасында төзелә торган килешү нигезендә Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә бирелә.

10. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

нәтиҗәлелек күрсәткеченең мәгънәсе;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе һәм сроклары;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешү турында хисаплылык бирү вакытлары һәм формалары;

нәтиҗәлелек күрсәткеченең билгеләнгән мәгнәсенә ирешмәү нәтиҗәләре;

Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә вәкаләтле органы тарафыннан килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлардан файдалану йөкләмәләренең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

11. Башка бюджетара трансфертлар күләме ($С_м$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$С_м = \sum_{i=1}^{n} Km_i \times 6{,}71,$$

монда:

$Km_i$ – Әлмәт шәһәре территориясендә җайга салына торган тарифлар буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контракт яисә шартнамә нигезендә 2022 елга маршрутлар буенча транспорт чарасының i-төре йөгереше һәм даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты карталарын алу хокукы;

6,71 – транспорт чараларының 1 км юлына алынмаган керемнәрне каплау ставкасы;

i – транспорт чарасының төре;

n – транспорт чаралары төрләре саны.

Әлмәт муниципаль районы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган бюджет ассигнованиеләреннән һәм бюджет йөкләмәләре лимитларыннан арта алмый.

12. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына күчерелә.

13. Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә вәкаләтле органы 2023 елның 1 гыйнварына Әлмәт муниципаль районы бюджетының финанслар белән тәэмин итү

чыганагы булып башка бюджетара трансфертлар торган чыгымнарын гамәлгә ашыру турындагы һәм нәтиҗәлелек күрсәткеченең ирешелгән мәгънәсе турындагы хисапларны килешүдә каралган тәртип һәм форма нигезендә Министрлыкка тапшыра.

14. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү килешүдә билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткече мәгънәсен 2022 ел йомгаклары буенча фактта ирешелгән нәтиҗәлелек күрсәткече мәгънәсе белән чагыштыру аша гамәлгә ашырыла.

15. Әлмәт муниципаль районының вәкаләтле җирле үзидарә органы тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

16. 2023 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2023 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемен күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемен түләтелергә тиеш.

17. 2023 елның 1 гыйнвары хәленә карата Әлмәт муниципаль районының вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта, башка бюджетара трансфертлар 2023 елның 1 апреленә кадәр Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

18. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

19. Башка бюджетара трансфертлар һәм (яисә) Әлмәт муниципаль районының вәкаләтле җирле үзидарә органы аларны бирү шартларын максатчан файдаланмаган очракта, шул исәптән Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы тарафыннан әлеге Тәртипнең 16 һәм 17 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына акчалар кермәгән очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган чаралар кулланыла.

20. Башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

______________________________